АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«_28_» __июня___2019 г.** № ___27___

Казан

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы карамагында журналистларны аккредитацияләү Кагыйдәләрен раслау турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 маддәсе нигезендә:

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы карамагында журналистларны аккредитацияләү Кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының беренче урынбасары И.М. Галиевка йөкләргә.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 2019 елның __28.06___ №__27__ боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы карамагында журналистларны аккредитацияләү Кагыйдәләре**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 маддәсенә нигезләнеп Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы карамагында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлый (алга таба – аккредитация, агентлык).

1.2. Аккредитация срогы чикләнмәгән. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге белән аккредитация конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәкле срокка (вакытлы аккредитация) тормышка ашырылырга мөмкин.

II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитациягә милек формасына һәм нигез салучыларның составына, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чараларының бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен аңа Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршындагы аккредитацияләүне алырга кирәк.

III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитация алу өчен гариза Агентлыкка, агентлык тарафыннан әлеге гаризаны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы белән тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, эш һәм мобиль телефоннар, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турындагы таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлы аккредитациягә гаризада шулай ук редакция биреме һәм аны үтәү периоды күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитацияне раслаучы документларның күчермәләре куела.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация турында карар агентлык җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – җитәкче) тарафыннан гариза кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар тиешле җитәкче боерыгы чыккан көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә, редакция тарафыннан аны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Аккредитация массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда булган очракта (реклама тарату, эротик басмалар) бирелми.

3.6. Аккредитация турындагы гаризаны карау, аккредитация турында агентлык җитәкчесе боерыгы проектын әзерләү (аккредитацияләүне бирмәү), шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә хәбәр итү әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәге хокукларга ия:

чарада катнашу;

агентлык карамагында булган чара турында рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистика, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышу;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, чараның регламентын үтәргә һәм аның барышына комачауламаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

агентлык тарафыннан бирелгән публикацияләрдә (эфирда эшләү) пресс-релизларны, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материалларны файдаланганда мәгълүмат чыганагына таянырга;

үз һөнәри эшчәнлегеңне тормышка ашырганда агентлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.